ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 09.12.2016 г. Казань № 4-2/г

2017 елга Татарстан Республикасы халкына, көнкүреш ихтыяҗлары өчен сатылучы сыекландырылган газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында

1999 елның 31 мартындагы «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында»гы федераль законга ярашлы рәвештә, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 1995 елның 15 апрелендәге «Җитештерү өчен газ һәм чималга бәяләрне дәүләт көйләвен тәртипкә салу буенча чаралар турында»гы 332нче карары белән, 2007 елның 15 июнендәге «Көнкүреш ихтыяҗлары өчен халыкка сатылучы сыекландырылган газга ваклап сату бәяләрен көйләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында»гы тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 129-э/2нче әмере, 2010 елның 15 июнендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 468нче карары белән расланган Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты Положениесе белән, Татарстан Республикасының тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына сатылучы сыекландырылган газга ваклап сату бәяләрен календарь көннәргә бүлеп (НДСны исәпкә алып) түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1. 2017 елның 1 гыйнварыннан алып 2017 елның 30 июненә кадәр:

- кулланучыларны газ белән тәэмин итү буенча транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча 1 килограммын 26,62 сумнан;

- кулланучыларны тәэмин итү буенча транспорт чыгымнарын исәпкә алып 1 килограммын 30,84 сумнан;

1.2. 2017 елның 1 июленнән алып 2017 елның 31 декабренә кадәр:

- кулланучыларны газ белән тәэмин итү буенча транспорт чыгымнарын исәпкә алмыйча 1 килограммын 27,66 сумнан;

- кулланучыларны газ белән тәэмин итү буенча транспорт чыгымнарын исәпкә алып 1 килограммын 32,04 сумнан.

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә кертелә.

Рәис М.Р.Зарипов